ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 август, 2024 ел № 35/6

Яшьләр эшләре буенча шәһәр муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәләрне раслау хакында

«Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 14 августындагы 665 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 18 июнендәге 434 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Расларга:

1) яшьләр эшләре буенча шәһәр муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә;

2) яшьләр эшләре буенча шәһәр муниципаль учреждениеләре гомуми тармак эшче һөнәрләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә;

2. Көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Советының «Яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында нигезнамәләрне раслау һәм Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10 номерлы Карарын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 15.11.2018 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2018 елның 23 ноябрендәге 85 санында басылган;

2) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары һәм Шәһәр Советының аерым Карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 24 гыйнварындагы 29/6 номерлы Карарының 4 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында

http://pravo.tatarstan.ru 05.02.2019 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2019 елның 8 февралендәге 9, 13 февралендәге 10, «Шәһри Чаллы» газетасының 2019 елның 8 февралендәге 9 саннарында басылган;

3) Шәһәр Советының «Яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 августындагы 32/7 номерлы Карарының 1 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 09.08.2019 урнаштырылган;

4) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 27 декабрендәге 11/7 номерлы Карарының 1 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 14.01.2022 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2022 елның 19 гыйнварындагы 3, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 елның 19 гыйнварындагы 3 саннарында басылган;

5) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 8 декабрендәге 18/7 номерлы Карарының 4 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 21.12.2022 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2022 елның 21 декабрендәге 93, «Шәһри Чаллы» газетасының 2022 елның 21 декабрендәге 93 саннарында басылган;

6) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 29 мартындагы 22/7 номерлы Карарының 4 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 10.04.2023 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2023 елның 5 апрелендәге 23, «Шәһри Чаллы» газетасының 2023 елның 5 апрелендәге 23 саннарында басылган;

7) Шәһәр Советының «Шәһәр Советының муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү өлкәсендәге аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 6 декабрендәге 28/7 номерлы Карарының 2 пунктын, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru 19.12.2023 урнаштырылган, «Челнинские известия» газетасының 2023 елның 8 декабрендәге 90, «Шәһри Чаллы» газетасының 2023 елның 8 декабрендәге 90 саннарында басылган.

3.Әлеге Карар рәсми басылган көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән соң хасил булган хокукый мөнәсәбәтләр өчен гамәлдә дип билгеләргә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Шәһәр Советының
35/6 Карарына
1 нче кушымта
7 август, 2024 ел

# Яшьләр эшләре буенча шәһәр муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә яшьләр эшләре буенча шәһәр муниципаль учреждениеләр (алга таба – яшьләр эшләре буенча учреждениеләр) хезмәткәрләренең окладларын формалаштыру тәртибен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрнең шартларын һәм күләмнәрен, шулай ук аларны билгеләү критерийларын билгели.

2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

1) хезмәт өчен түләү системасы - федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү шартларын һәм күләмнәрен, база (вазыйфаи) окладлары күләмнәрен, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне дә кертеп, билгели торган нормалар җыелмасы;

2) база оклады - эшче һөнәре яисә җитәкче, белгеч, техник башкаручы вазыйфасы буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы, тиешле һөнәри квалификация төркеменә керүче яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренең компенсация һәм стимуллаштыру түләүләреннән тыш оклады;

3) вазыйфаи оклад - билгеле бер катлаулылыктагы хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәгән өчен календарь айда фактта эшләнгән вакыт өчен хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүнең компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен исәпкә алмыйча билгеләнгән күләме;

4) хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) - хезмәткәрнең квалификациясенә, башкарылган эшнең катлаулылыгына, санына, сыйфатына һәм шартларына карап, компенсация һәм стимуллаштыру түләүләрен дә кертеп, хезмәт өчен түләү;

5) компенсация характерындагы түләүләр – компенсация характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, шул исәптән нормаль шартлардан читләшкән шартларда эшләгән өчен һәм компенсация характерындагы башка түләүләр;

6) стимуллаштыру характерындагы түләүләр - стимуллаштыру характерындагы өстәмә түләүләр һәм өстәмәләр, премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре.

3. Яшьләр эшләре учреждениеләренең физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең, мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация

төркемнәре (алга таба тиешенчә - яшьләр эшләре буенча учреждениеләрнең физик культура хезмәткәрләре, мәгариф хезмәткәрләре, медицина хезмәткәрләре, мәдәният хезмәткәрләре) хезмәткәрләренең хезмәт хакы (хезмәткәрнең хезмәте өчен түләү) түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) вазыйфаи оклад;

2) стимуллаштыру характерындагы түләүләр;

3) компенсация характерындагы түләүләр.

4. Яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәренең профиль буенча хезмәт стажы артуга, белем алуга яки белем турындагы документларны яңадан торгызуга, квалификация категориясен бирүгә, мактаулы исем бирүгә, ведомствоның аерым хөрмәтләү билгеләре белән бүләкләнүгә бәйле рәвештә, ел саен бирелә торган яки башка ял вакытында, вакытлыча эшкә яраксызлык чорында, шулай ук уртача хезмәт хакы саклана торган башка чорларда барлыкка килгән хезмәт хакы күләме үзгәрүгә хокукы күрсәтелгән чордан соң гамәлгә ашырыла.

5. Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчеләре:

1) белем һәм хезмәт стажы (белгечлек буенча, билгеле бер вазыйфада эшләү) турындагы документларны һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерәләр;

2) ел саен яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренең тариф исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

3) яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын вакытында һәм дөрес билгеләү өчен җаваплы булып торалар.

## 2 бүлек. Яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләрнең база окладын билгеләү

6. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә физик культура хезмәткәрләренең база оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады, сум |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура һәм спорт хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Хореограф | 20 112 |

7. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә мәгариф хезмәткәрләренең база оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗәдәге укыту - ярдәмче персонал һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация | Укыту бүлеге секретаре | 19 515 |

| | | |
|---|---|---|
| дәрәҗәсе | | |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту - ярдәмче персонал һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Режим буенча дежур | 19 625 |
| | Кече тәрбияче | |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Хезмәт инструкторы | 20 705 |
| | Физик тәрбия инструкторы | |
| | Музыка җитәкчесе | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Концертмейстер | 20 800 |
| | Өстәмә белем бирү педагогы | |
| | Педагог-оештыручы | |
| | Социаль педагог | |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | 20 900 |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Тәрбияче | |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Тәрбия психологы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | 21 000 |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| | Өлкән тәрбияче | |
| Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга өстәмә белем белем бирү программасын гамәлгә ашыручы структура бүлекчәләре мөдире (башлыгы): кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, | 21 050 |

| | | |
|---|---|---|
| | сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-производство) остаханәсе һәм башка структура бүлекчәләре | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Балаларга өстәмә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структура бүлекчәсе мөдире (башлыгы) | 21 100 |

«Яшьләр белән эшләү белгече» һәм «яшьләр белән социаль эш белгече» вазыйфаларын биләгән хезмәткәрләрнең база окладына 20,800 сум.

8. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә медицина хезмәткәрләренең база окладына түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база окладына, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Диета буенча шәфкать туташы (диета буенча медбрат) | 20 663 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медбрат) | 21 163 |
| | Массаж шәфкать туташы (массаж медбраты) | |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Белгеч табиблар (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсендәге белгеч табиблардан кала) | 24 563 |

Яшьләр эшләре учреждениеләрендә медицина хезмәткәрләренең база окладына тармакның өстенлекле коэффициенты кулланыла. Тармакның өстенлекле коэффициенты 1,1.

Күрсәтелгән коэффициентны база окладына куллану яңа база окладына барлыкка китерә һәм компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне исәпләгәндә исәпкә алына.

9. Яшьләр эшләре учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләренең база окладына түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Айлык база оклады, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Билет тикшерүчеләр | 20 351 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 20 862 |
| Костюмнар бүлмәсе мөдире | 20 862 |
| Мәдәни оештыручы | 20 862 |
| Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | 20 862 |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор-концертмейстер | 21 362 |
| Тавыш операторы | 21 362 |
| Кинооператор | 21 362 |
| Китапханә, музей һәм башка шундый учреждение һәм оешмалар редакторы | 21 362 |
| Клуб эше методикасы белгече | 21 362 |
| Яктырту рәссамы | 21 362 |
| Рәссам-декоратор | 21 362 |
| Рәссам-бизәүче | 21 362 |
| Рәссам-фотограф | 21 362 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре җитәкчеләре составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый учреждение һәм оешмаларның бүлек | 22 562 |

| | |
|---|---|
| (сектор) мөдире | |
| Тавыш режиссеры | 22 562 |
| Режиссер-куючы | 22 562 |
| Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 22 562 |
| Массакүләм тамашалар режиссеры | 22 562 |
| Сәнгать җитәкчесе | 22 562 |

Яшьләр эшләре учреждениеләрендәге мәдәният хезмәткәрләренең база окладына тармакның өстенлекле коэффициенты кулланыла.

Тармакның өстенлекле коэффициенты:

«Ярдәмче состав техник башкаручылары һәм артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме буенча - 1.05;

«Мәдәният, сәнгать һәм урта звено кинематографиясе хезмәткәрләре вазыйфалары» һәм «әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркемнәре буенча - 1,12;

«Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазыйфасы» һөнәри квалификация төркеме буенча - 1,25.

Әлеге коэффициентларны база окладына карата куллану яңа база окладына булдыра һәм компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр исәпләнгәндә исәпкә алына

10. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә хезмәткәрләренең эш вакыты Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары белән билгеләнә.

11. Яшьләр эшләре учреждениеләренең физик культура, мәгариф, медицина һәм мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times H_n,$$

монда

$O_b$ - яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренең база оклады күләме;

$H_n$ - әлеге вазыйфа буенча эш күләменә туры китереп, база оклады өчен сәгать нормасы.

## 3 бүлек. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр

12. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр хезмәткәрне югары сыйфатлы эш нәтиҗәләренә ирешүгә стимуллаштыруга юнәлтелгән түләүләрне, шулай ук башкарылган эш өчен бүләкләүне үз эченә ала.

13. Стимуллаштыру характерындагы түләүләргә керә:

1) квалификация категориясе өчен түләүләр;
2) профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр;
3) мактаулы исемнәр, спорт исемнәре өчен түләүләр;
4) хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр;
5) премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре;
6) башкарылган эш сыйфаты өчен түләүләр.

13. «Яшьләр белән эшләү белгече» һәм «яшьләр белән социаль эш белгече» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр яшьләр эшләре учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләренең икенче квалификация дәрәҗәсендәге педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларына түләүләргә охшаш рәвештә исәпләнә.

14. «Труппа мөдире», «вокал буенча репетитор», «балет буенча репетитор», «артист-вокалист (солист)», «балет артисты», «оркестр артисты», «хор артисты», «драма артисты», «симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестрлар, халык уен кораллары оркестры артисты», «җыр һәм бию ансамбльләре оркестры артисты», «эстрада оркестры (ансамбль) артисты», «җыр һәм бию ансамбле, бию коллективы балеты артисты», «җыр һәм бию ансамбле хоры, хор коллективы артисты» «артистлар - концерт башкаручылары (барлык жанрларда), ярдәмче составтагы концерт башкаручы артистлардан тыш вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр яшьләр эшләре учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләренең әйдәүче звеносының мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларына түләүләргә охшаш рәвештә исәпләнә.

15. «Баш дирижер», «баш режиссер», «әдәби-драматургия өлеше җитәкчесе», «музыка өлеше мөдире» вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы түләүләр мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең яшьләр эшләре учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләре җитәкчеләре составы хезмәткәрләре вазыйфаларына түләүләргә охшаш рәвештә исәпләнә.

## 4 бүлек. Яшьләр эшләре буенча муниципаль учреждениеләрнең физик культура һәм спорт хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм аларны бирү тәртибе.

16. Физик культура хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) квалификация категориясенең гамәлдәге квалификация категориясе чикләрендә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләренең физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаи окладгы;

$D_{kk}$ - 1 нче таблицада бирелгән тәртиптә квалификация категориясе өчен өстәмә күләме.

1 нче таблица

Физик культура хезмәткәрләренең квалификация категориясе өчен өстәмә күләме

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| | югары квалификация категориясе | 8,5 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

17. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$ ) профиль буенча эш вакытына карап билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләренең физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - 2 нче таблицада бирелгән тәртиптә профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмә күләме.

2 нче таблица

Профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмә күләме.

| Һөнәри квалификация төркеме исеме һәм һөнәри стандартлар буенча вазыйфалар исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләр вазыйфалары (2 төркем) | икенче | 2 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | | 5 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | | 15 елдан артык | 5,5 |

Хезмәт стажы үзгәргәндә профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән яисә стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

18. Физик культура хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр, спорт исемнәре өчен түләүләр ($B_{pz}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләренең физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәргә һәм спорт исемнәренә ия булган өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Физик тәрбия хезмәткәрләренә түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр һәм спорт исемнәре исемлеге әлеге Нигезләмә кушымтасының 1 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәргә һәм спорт исеменә ия булган өчен түләү күләме мактаулы исем яки спорт исеме бирелгән көннән билгеләнә. Ике яки аннан да күбрәк мактаулы исемгә, спорт исемнәренә ия булган хезмәткәрләр өчен, алар өчен түләү хезмәткәр сайлаган бер нигез буенча билгеләнә.

19. Физик тәрбия хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр ($B_{it}$) билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times \frac{D_{it}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләренең физик культура хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{it}$ - дәүләт бүләкләре һәм спорт исемнәре өчен өстәмә күләме.

5 бүлек. Яшьләр эшләре учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме һәм аларны билгеләү тәртибе.

20. Мәгариф хезмәткәрләренә квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) квалификация категориясенең гамәлдәге квалификация категориясе чикләрендә бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{kk}$ - 3 нче таблицада күрсәтелгән тәртиптә квалификация категориясе өчен өстәмә күләме.

3 нче таблица

Мәгариф хезмәткәрләренең квалификация категориясе өчен өстәмә күләме

| Квалификация дәрәҗәсе | Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| | югары квалификация категориясе | 7,5 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 7,5 |
| | югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Өченче | беренче квалификация категориясе | 8,5 |
| | югары квалификация категориясе | 12,5 |
| Дүртенче | беренче квалификация категориясе | 10,0 |

| | | |
|---|---|---|
| | югары квалификация категориясе | 15,0 |
| Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче | беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| | югары квалификация категориясе | 15,0 |
| Икенче | беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| | югары квалификация категориясе | 15,0 |

Квалификация категориясе өчен түләүләрне билгеләү (үзгәртү) тиешле аттестация комиссиясе тарафыннан уңай карар кабул ителгән көннән башкарыла.

21. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - 4 нче таблицада күрсәтелгән тәртиптә хезмәт стажы өчен өстәмә күләме.

4 нче таблица

Профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмә күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфалары | беренче - дүртенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | 15 елдан артык | 6,5 |
| Структура бүлекчәсе башлыклары вазыйфалары | беренче-икенче | 2 елдан 6 елга кадәр | 3,0 |
| | | 6 елдан 10 елга кадәр | 4,5 |
| | | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,5 |
| | | 15 елдан артык | 6,5 |

Хезмәт стажы үзгәргәндә профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән яисә стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

Педагогик хезмәт стажына мәгариф оешмаларында һәм башка оешмаларда педагогик, җитәкчелек һәм методик эш 5 нче таблицада каралган тәртиптә кертелә.

5 нче таблица

Аларда эшләгән вакыт мәгариф хезмәткәрләренең педагогик стажына кертелә торган оешмалар һәм вазыйфалар исемлеге

| Оешма исеме | Вазыйфа исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Мәгариф оешмалары (шул исәптән югары белем бирү оешмалары, югары хәрби белем бирү оешмалары һәм хәрби профессиональ белем бирү оешмалары, белгечләргә өстәмә профессиональ белем бирү (квалификация күтәрү) оешмалары;<br>медицина оешмалары һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары: балалар йортлары, балалар санаторийлары, клиникалары, поликлиникалары, больницалары һ.б. | Укытучылар, укытучы-дефектологлар, укытучы-логопедлар (логопедлар), укытучы-оештыручылар (тормыш иминлеге нигезләре, хәрби хезмәткә чакырылуга кадәр әзерлек), физик тәрбия җитәкчеләре, өлкән мастерлар, производствога өйрәтү осталары (шул исәптән транспорт чараларын йөртүгә, авыл хуҗалыгы машиналарында эшләргә, язу машиналарында эшләргә һәм башка оештыру техникасында эшләргә өйрәтү), өлкән методистлар, методистлар, өлкән инструктор-методистлар, инструктор-методистлар (шул исәптән физик культура һәм спорт, туризм буенча), концертмейстерлар, музыка җитәкчеләре, өлкән тәрбиячеләр, тәрбиячеләр, сыйныф тәрбиячеләре, социаль педагоглар, педагог-психологлар, педагог-оештыручылар, өстәмә белем бирү педагоглары, өлкән тренер-укытучылар, |

| | |
|---|---|
| | тренер-укытучылар, өлкән вожатыйлар (пионервожатыйлар), физкультура буенча инструкторлар, хезмәт буенча инструкторлар, директорлар (башлыклар, мөдирләр), директор урынбасарлары (башлыклар, мөдирләр) укыту, укыту-тәрбия, укыту-җитештерү буенча, тәрбия, мәдәни-тәрбия эше, производствода укыту (эш), чит тел, укыту-очу әзерлеге буенча, гомуми белем бирү әзерлеге буенча, режим буенча, эшчәнлеге белем бирү (тәрбия) процессына, методик тәэмин итүгә бәйле булган уку-консультация пунктлары, логопедик пунктлар, интернатлар, бүлекләр, бүлекчәләр, лабораторияләр, кабинетлар, секцияләр, филиаллар, курслар һәм башка структура бүлекчәләре мөдирләре, практика мөдирләре (башлыклары), режим буенча өлкән дежур торучылар, режим буенча дежур торучылар, аккомпаниаторлар, мәдәни оештыручыылар, экскурсоводлар, профессор-укытучылар составы |
| Барлык төрдәге методик (укыту- методик) оешмалар (ведомство буйсынуына карамастан) | Җитәкчеләр, аларның урынбасарлары, секторлар, кабинетлар, лабораторияләр, бүлекләр мөдирләре; эшчәнлекләре методик тәэмин итү белән бәйле булган фәнни хезмәткәрләр; өлкән методистлар, методистлар |
| Мәгариф оешмалары белән идарә итүче органнар һәм мәгариф идарә органнары (структура бүлекчәләре) | Идарә итү, инспектор, методик позицияләр, инструктор позицияләре, һәм башка белгеч позицияләр (икътисадый, финанс, бизнес эшчәнлеге, төзелеш, тәэмин итү, офис эше белән бәйле позицияләрдә эштән кала) |
| Производствога кадрлар әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү мәсьәләләре белән шөгыльләнүче техник укыту бүлекләре (бюролары), республика башкарма хакимияте органнары оешмаларының, бүлекчәләренең кадрлар бүлекләре | Эшчәнлекләре квалификация күтәрү һәм әзерләү мәсьәләләре белән бәйле булган штатлы укытучылар, эшчеләрне производствода укыту осталары, җитәкче, инспектор, инженер, методик вазыйфалар |

| | |
|---|---|
| РОСТО (ДОСААФ) гражданнар авиациясе белем бирү оешмалары | Җитәкче, команда-очу, команда-инструктор, инженер-инструктор, инструктор һәм укытучылар составы, производствога өйрәтү осталары, инженер-инструктор-методистлар, инженер-очучы-методистлар |
| Учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмаларның тулай торaклары, торак-эксплуатация оешмалары, яшьләр торак комплекслары, балалар кинотеатрлары, яшь тамашачы театрлары, курчак театрлары, мәдәни-агарту оешмалары һәм предприятиеләр һәм оешмаларының балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү бүлекчәләре | Тәрбиячеләр, педагог-оештыручылар, педагог-психологлар (психологлар), укытучылар, балалар һәм яшүсмерләр өчен өстәмә белем бирү педагоглары (түгәрәк җитәкчеләре), инструкторлар һәм инструктор-методистлар, тренер-укытучылар һәм балалар һәм яшүсмерләр белән эшләү буенча башка белгечләр, балалар бүлекләре, секторлар мөдирләре |
| Төзәтү колонияләре, тәрбия колонияләре, тикшерү изоляторлары һәм төрмәләр, дәвалау-төзәтү оешмалары | Педагогик белем булганда түбәндәге вазыйфаларда эш (хезмәт): тәрбия эше буенча башлык урынбасары, отряд башлыгы, өлкән инспектор, гомуми белем бирү (укыту) буенча инспектор, өлкән инспектор-методист һәм инспектор-методист, производство-техник укыту буенча өлкән инженер һәм инженер, өлкән мастер һәм производствога өйрәтү мастеры, өлкән инспектор, саклау һәм режим буенча инспектор, укыту-техник кабинет мөдире, психолог |
| Искәрмә:<br>Педагогик эш стажына кертелә:<br>өлкәннәр өчен социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмаларда һәм медицина оешмаларында укытучы-дефектолог, логопед, тәрбияче, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау оешмаларының оештыру-методик бүлеге методистлары булып эшләү вакыты;<br>СССР һәм Россия Федерациясенең Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, югары белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында түбәндәге тәртиптә уку вакыты;<br>педагогик хезмәткәрләргә педагогик хезмәт стажы бернинди шартлар һәм чикләүләрсез исәпләнә:<br>контракт буенча хәрби хезмәт үтү вакытында - бер хәрби хезмәт көне бер көн эш көне, хәрби чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакыты - бер хәрби хезмәт көне ике хезмәт көне хисабыннан; | |

| |
|---|
| фильмотека мөдире һәм фильмотека методисты вазыйфасында эшләү вакыты;<br>аерым яки гомуми алганда, түбәндәге чорларга кадәр һәм аннан соң педагогик эшчәнлек алып барылган очракта педагогик хезмәткәрләрнең педагогик хезмәт стажында түбәндәге чорлар исәпкә алына:<br>Контракт буенча һәм чакырылыш буенча хәрби хезмәттә булу вакытыннан тыш, СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә офицер, сержант, старшина составларында прапорщиклар һәм мичманнар (шул исәптән Эчке эшләр министрлыгы гаскәрләрендә, куркынычсызлык органнарында һәм гаскәрләрдә) хезмәт итү чоры;<br>Россия Федерациясе халык мәгарифе һәм фән хезмәткәрләре профсоюзының (агарту, югары мәктәп һәм фәнни оешмалар) территориаль оешмалары аппаратларында (комитетларда, советларда) белгечләрнең җитәкче, инспекторлык, инструкторлык һәм башка вазыйфаларында; профсоюз органнарында сайланулы вазыйфаларда; педагогик җәмгыятьләрдә һәм Балалар фонды идарәләрендә инструкторлык һәм методик вазыйфаларда; Укытучы (халык мәгарифе, һөнәри техник белем бирү хезмәткәре) йорты директоры (мөдире) вазыйфасында; балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләрендә яки балигъ булмаганнарны социаль-хокукый яклау бүлекләрендә, Эчке эшләр органнарының хокук бозуларны кисәтү бүлекчәләрендә (балигъ булмаганнар эшләре буенча инспекция, милициянең балалар бүлмәсе) эш чоры |

Аерым категория педагогик хезмәткәрләрнең педагогик хезмәт стажына СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү һәм оешмаларда белем бирү оешмасындагы эш юнәлешенә яки укытыла торган фәннең (курс, дисциплинаның, түгәрәкнең) профиленә туры килә торган эш чоры исәпләнә:

укытучы-оештыручыларга (тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре, армиягә кадәр әзерлек нигезләре);

физик тәрбия укытучыларына, физик тәрбия җитәкчеләренә, физкультура инструкторларына, инструктор-методистларга (өлкән инструктор-методистларга), тренер-укытучылага (өлкән тренер-укытучыларга);

укытучыларга, хезмәт (һөнәр) укытучыларына, технология, сызым, сынлы сәнгать, информатика, махсус фәннәр, шул исәптән аерым фәннәрне тирәнтен өйрәнүле гомуми белем бирү оешмаларының (сыйныфларының) махсус фәннәр укытучыларына;

производствога өйрәтү осталарына;

өстәмә белем бирү педагогларына

эксперименталь белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;

педагог-психологларга;

методистларга;

мәдәният һәм сәнгатьнең урта звеносы (бүлекләре) музыкаль-педагогик, нәфис-график, музыкаль белгечләр әзерләү программалары буенча белгечләр әзерләүче урта һөнәри белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә;

балаларга өстәмә белем бирү оешмалары (мәдәният һәм сәнгать, шул исәптән музыка һәм сәнгать) укытучыларына, музыка һәм сәнгать гомуми белем бирү

оешмаларының махсус дисциплиналары укытучыларына, педагогика училищеларының (педагогика көллиятләренең) музыка дисциплиналары укытучыларына, музыка җитәкчеләренә, концертмейстерларга.

Тәрбияче ярдәмчесе һәм кече тәрбияче вазыйфаларында эшләү вакыты, әлеге вазыйфаларда эшләгән чорда хезмәткәрнең педагогик белеме булган, яки ул югары белем бирү оешмасында яки һөнәри белем бирү оешмасында укыган очракта, педагогик хезмәт стажына керә.

Оешма хезмәткәрләренең педагогик эш вакыты мәгариф оешмаларында төп эш урыныннан тыш сәгатьләп түләү шартында эшләнгән эш күләме(бер яки берничә белем бирү оешмасында), уку елы дәвамында 180 сәгатьтән дә ким булмаса, педагогик стажга кертелә.

Шул ук вакытта педагогик стажга педагогик эш башкарган айлар гына кертелә.

СССР һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итү, учреждение һәм оешмаларда эшләүнең укытыла торган профильгә (курс, дисциплина, түгәрәк) туры килүе турындагы конкрет мәсьәләләрне хәл итү хокукы профсоюз органы белән килештереп яшьләр эшләре учреждениесе җитәкчесенә бирелә.

22. Яшьләр эшләре учреждениеләренең мәгариф хезмәткәрләренә Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш һәм автономияле республикаларның мактаулы исемнәре һәм Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре өчен түләүләр ($B_{pz}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәргә һәм спорт исемнәренә ия булган өчен өстәмә күләме.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Татарстан Республикасының (Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы) мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең ведомство бүләкләре, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре, Совет Социалистик Республикалар Союзының ведомство бүләкләре өчен өстәмә күләме 4 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең Мактау грамотасы өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. Россия Федерациясенең Мактау грамотасы өчен өстәмә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министры (Россия Федерациясе мәгариф министры)

боерыгы белән бүләкләнә торган мәгариф хезмәткәрләренә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының) ведомство бүләкләре белән бүләкләү тәртибе нигезендә билгеләнә.

«Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе өчен өстәмә күләме 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлары өчен» күкрәк билгесе булган өчен өстәмә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.

Мәгариф хезмәткәрләренә стимуллаштыру түләүләре бирелә торган мактаулы исемнәр һәм ведомство бүләкләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 2 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәргә һәм ведомство бүләкләренә ия булган өчен түләү күләмен билгеләү мактаулы исем һәм ведомство бүләге бирелгән көннән башкарыла. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исем, ике һәм аннан да күбрәк ведомство бүләге булган хезмәткәрләргә түләү, хезмәткәр сайлавы нигезендә, шуларның берсе буенча билгеләнә.

23.Мәгариф хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр ($B_{it}$) билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times \frac{D_{it}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{it}$ - 6 нчы таблицада күрсәтелгән хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме, 6 нчы таблицада китерелгән.

6 нчы таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | - | 41,0 |
| Икенче дәрәҗәдәге укыту-ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 41,0 |

| | | |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче - дүртенче | 41,0 |
| Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | беренче | 46,0 |
| | икенче | 49,0 |

Мәгариф хезмәткәрләренә девиант тәртипле балалар өчен яшьләр эшләре учреждениеләрендә эшләгән өчен түләүләр ($B_{dp}$) билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә

$$B_{dp} = O_d \times \frac{D_{dp}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре мәгариф хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{dp}$ - девиант тәртипле балалар өчен яшьләр эшләре учреждениеләрендә эшләгән өчен өстәмә күләме 4,5 процент.

## 6 бүлек. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә медицина хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләү тәртибе һәм күләме

24. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри квалификация төркемнәре киселешендә аттестация нәтиҗәләре буенча квалификация категорияләре бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче хезмәткәрләргә бирелә. Квалификация категориясе өчен түләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладе;

$D_{kk}$ - 7 нче таблицада күрсәтелгән тәртиптә квалификация категориясе өчен өстәмә күләме.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла

7 нче таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 3,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 6,0 |
| Югары квалификация категориясе | 10,0 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | |
| Икенче квалификация категориясе | 6,0 |
| Беренче квалификация категориясе | 10,0 |
| Югары квалификация категориясе | 20,0 |

21. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - 8 нче таблицада бирелгән тәртиптә профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмә күләме.

8 нче таблица

Профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмә күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы | 3 елдан 5 елга кадәр | 2,5 |
| | 5 елдан 10 елга | 3,5 |

| | | |
|---|---|---|
| | кадәр | |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 4,5 |
| | 15 елдан артык | 5,5 |
| Табиблар һәм провизорлар | 3 елдан 5 елга кадәр | 5,0 |
| | 5 елдан 10 елга кадәр | 7,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 9,0 |
| | 15 елдан артык | 10,0 |

Хезмәт стажы үзгәргәндә профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән яисә стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

26. Медицина хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр өчен түләүләр ($B_{pz}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{pz}$ - дәүләт бүләкләре өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Медицина хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 3 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр өчен түләү күләме мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме булган хезмәткәрләргә түләү, хезмәткәр сайлавы нигезендә, шуларның берсе буенча билгеләнә.

23.Медицина хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр ($B_{it}$) билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times \frac{D_{it}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_{it}$ - 41,0 процент күләмендә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме.

7 бүлек. Яшьләр эшләре учреждениеләренең мәдәният хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр билгеләү тәртибе һәм күләме

28. Квалификация категориясе өчен түләүләр ($B_{kk}$) тариф-квалификация характеристикалары нигезендә һөнәри-квалификация төркемнәре киселешендә аттестация йомгаклары буенча квалификация категорияләре бирүне күздә тоткан белгечлекләр буенча эшләүче мәдәният хезмәткәрләренә бирелә. .Квалификация категориясе өчен түләү түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{kk} = O_d \times \frac{D_{kk}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре медицина хезмәткәрләренең вазыйфаи окладаы;

$D_{kk}$ - 9 нчы таблицада бирелгән квалификация категориясе өчен бонус күләме.

Квалификация категориясе өчен түләүләрне үзгәртү (билгеләү) аттестация комиссиясе төзелгән орган (учреждение) боерыгы датасы нигезендә башкарыла

9 нчы таблица

Квалификация категориясе өчен өстәмә күләме

| Квалификация категориясе | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация категориясе | 7,5 |
| Югары квалификация категориясе | 12,5 |

29. Профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр ($B_s$) профиль буенча эш дәвамлылыгына бәйле рәвештә һөнәри квалификация төркемнәре һәм квалификация дәрәҗәләре киселешендә билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_s = O_d \times \frac{D_s}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи оклады;

$D_s$ - 10 нче таблицада күрсәтелгән тәртиптә хезмәт стажы өчен өстәмә күләме.

10 нчы таблица

Профиль буенча хезмәт стажы өчен өстәмә күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Стаж буенча төркем | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,5 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 2,0 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 2,5 |
| | 15 елдан артык | 3,5 |
| Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалар» һөнәри квалификация төркеме | 3 елдан 6 елга кадәр | 1,5 |
| | 6 елдан 10 елга кадәр | 3,5 |
| | 10 елдан 15 елга кадәр | 5,0 |
| | 15 елдан артык | 6,5 |

Хезмәт стажы үзгәргәндә профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен билгеләү (үзгәртү), стажны раслаучы документлар оешмада булса, профиль буенча хезмәт стажы өчен түләүләр күләмен арттыру хокукы бирә торган стажга ирешкән көннән яисә стажны раслаучы кирәкле документ тапшырылган көннән башкарыла.

30. Мәдәният хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр өчен түләүләр ($B_{pz}$) бирелә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{pz} = O_d \times \frac{D_{pz}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре мәдәният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_{pz}$ - мактаулы исемнәр өчен өстәмә күләме.

Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы автономияле республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 6 процент тәшкил итә.

Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзының мактаулы исемнәре, Совет Социалистик Республикалар Союзы составындагы союздаш республикаларның мактаулы исемнәре өчен өстәмә күләме 7 процент тәшкил итә.

Мәдәният хезмәткәрләренә тиешле түләүләр бирелә торган мактаулы исемнәр исемлеге әлеге Нигезләмәгә кушымтаның 4 нче таблицасында китерелгән.

Мактаулы исемнәр өчен түләү күләме мактаулы исем бирелгән көннән билгеләнә. Ике һәм аннан да күбрәк мактаулы исеме булган хезмәткәрләргә түләү, хезмәткәр сайлавы нигезендә, шуларның берсе буенча билгеләнә.

31.Мәдәният хезмәткәрләренә хезмәт интенсивлыгы өчен түләүләр ($B_{it}$) билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$B_{it} = O_d \times \frac{D_{it}}{100\%},$$

монда

$O_d$ - яшьләр эшләре учреждениеләре мәлəният хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлы;

$D_{it}$ - 11 нче таблицада күрсәтелгән тәртиптә хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме.

11 нче таблица

Хезмәт интенсивлыгы өчен өстәмә күләме

| Һөнәри квалификация төркеменең исеме | Вазыйфа исеме | Өстәмә күләме, процент |
|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| «Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 41,0 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | аккомпаниатор, костюмнар бүлмәсе мөдире | 49,0 |
| | Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе, мәдәни оештыручы | 61,0 |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0 |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре җитәкчеләре составы вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | барлык вазыйфалар | 49,0 |

32.Яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренә юбилей даталары, хөрмәтләү билгеләре, рәхмәт хатлары, грамоталар, дәүләт бүләкләре алу сәбәпле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк килешүләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча премияләр һәм башка кызыксындыру түләүләре төп эш урыны буенча аерым вакыт (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.

33. Эш йомгаклары буенча премиаль һәм башка кызыксындыру түләүләренең күләме, тәртибе һәм шартлары яшьләр эшләре учреждениеләренең локаль актлары һәм күмәк килешүләре белән билгеләнә.

34. Яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренә премиаль түләүләргә каралган хезмәт өчен түләү фонды төп эш урыны һәм төп вазыйфалары буенча хезмтәкәрләргә окладлар (вазыйфаи окладлар) һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләргә каралган хезмәт хакы фондының кимендә 2 процентын тәшкил итә.

35.Яшьләр эшләре учреждениеләрендә физик культура хезмәткәрләренә, мәгариф хезмәткәрләренә, медицина хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча билгеле бер вакыт аралыгында хезмәт нәтиҗәләре буенча билгеләнә. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләр күләменә йогынты ясый торган төп критерий булып яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларының иң чик күрсәткечләренә ирешү тора.

36. Яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренең эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары яшьләр учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан раслана. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары һәм түләүләрне гамәлгә ашыру шартлары ел саен оешма алдына куелган бурычлар нигезендә билгеләнә.

37. Башкарылган эш сыйфаты өчен түләүләр күләме, процедурасы һәм шартлары оешманың локаль норматив актлары һәм коллектив килешүләр белән билгеләнә.

38. Башкарылган эш сыйфаты өчен түләүләр ($B_{k_j}$) түбәндәге формула ярдәмендә исәпләнә:

$$B_{k_j} = \frac{FOT_k}{\sum_{i=1}^{n}\sum_{j=1}^{m}\left(I_{ij} \times K_i\right)} \times \sum_{i=1}^{n}\left(I_{ij} \times K_i\right),$$

монда

$FOT_k$ - башкарылган эш сыйфаты өчен түләүләр өчен хезмәт хакы фонды;

$I_{ij}$ - j-хезмәткәрнең эш нәтиҗәлелеген бәяләү өчен нормалаштырылган I-критерий;

$K_i$ - эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен I-критерийның чагыштырма үлчәм коэффициенты;

n - эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийлары саны;

м - яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләре саны.

39. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критерийларын нормалаштыру төрле үлчәмдәге нәтиҗәлелек критерийларының чагыштырылуын тәэмин итә. Нормалаштыру эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие (иң яхшы һәм иң начар) күрсәткечләре диапазонын сайлаудан гыйбарәт, аларның берсе нормалаштырылган критерийның нуль күрсәткеченә, икенчесе берәмлеккә туры килә. Нәтиҗәлелек критериеның фактагы зурлыгы эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие күрсәткечләре диапазоны чикләрендә булганда, эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерие нульдән алып бергә кадәр күрсәткечләрне кабул итә. Нәтиҗәлелек критериеның фактагы зурлыгы иң начар күрсәткечтән түбән булганда нормалаштырылган критерийның кыйммәте нуль, иң яхшысыннан югарырак булганда - бер итеп кабул ителә.

40.Эшчәнлек нәтиҗәлелегенең нормалаштырылган критерий зурлыгынын эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерие зурлыгына бәйлелеге турыдан-туры (уңай динамика критерийның зурлыгын арттыру белән билгеләнә) һәм тискәре (уңай динамика критерийның зурлыгын кимету белән билгеләнә) булырга мөмкин.

41. Критерий зурлыгына турыдан-туры бәйле булганда, нормалаштырылган критерий ($I_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

монда

$FI_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең факттагы зурлыгы;

$M_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең иң яхшы зурлыгы;

$L_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең иң начар зурлыгы.

42. Критерий зурлыгына тискәре бәйлелелектә булганда, нормалаштырылган критерий ($I_i$)түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$I_i = 1 - \frac{FI_i - L_i}{M_i - L_i},$$

монда

$FI_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең факттагы зурлыгы;

$M_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең иң яхшы зурлыгы;

$L_i$ - эшчәнлек нәтиҗәлелеге критериесенең иң начар зурлыгы.

43. Эшчәнлекнең нәтиҗәлелеге критериесенең өстенлекле дәрәҗәсе авырлык коэффициентлары белән билгеләнә Иң өстенлекле критерийга иң зур коэффициент бирелә. Чагыштырма үлчәм коэффициенты ($K_i$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$K_i = \frac{VK_i}{\sum_{i=1}^{n} VK_i},$$

монда $VK_i$ - эшчәнлекнең эффективлыгын бәяләү өчен i-критерийның үлчәм коэффициенты.

44. хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәү коэффициентларының иң чик күләме 12-15 нче таблицаларда китерелгән.

12 нче таблица

Физик культура хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| Вазыйфа исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗә физик культура һәм спорт хезмәткәрләре һөнәри квалификация төркеме | | |

| | | |
|---|---|---|
| Хореограф | икенче | 50 |

13 нче таблица

Мәгариф хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| N т / б | Вазыйфа исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Беренче дәрәҗә укыту - ярдәмче персонал һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 1.1. | Укыту бүлеге секретаре | беренче | 5 |
| Икенче дәрәҗә укыту - ярдәмче персонал һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 2.1. | Режим буенча дежур | беренче | 35 |
| 2.2. | Кече тәрбияче | икенче | 35 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 3.1. | Хезмәт инструкторы | беренче | 45 |
| 3.2. | Физик тәрбия инструкторы | беренче | 45 |
| 3.3. | Музыка җитәкчесе | беренче | 45 |
| 3.4. | Концертмейстер | икенче | 50 |
| 3.5. | Өстәмә белем бирү педагогы | икенче | 50 |
| 3.6. | Педагог-оештыручы | икенче | 50 |
| 3.7. | Социаль педагог | икенче | 50 |
| 3.8. | Тренер-укытучы | икенче | 50 |
| 3.9. | Инструктор-методист | икенче | 50 |
| 3.10. | Яшьләр белән эшләү буенча белгеч | икенче | 50 |
| 3.11. | Яшьләр белән социаль эш белгече | икенче | 50 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3.12. | Методист | өченче | 55 |
| 3.13. | Өлкән инструктор-методист | өченче | 55 |
| 3.14. | Тәрбияче | өченче | 55 |
| 3.15. | Өлкән тренер-укытучы | өченче | 55 |
| 3.16. | Тәрбия психологы | өченче | 55 |
| 3.17. | Өлкән методист | дүртенче | 60 |
| 3.18. | Укытучы-логопед (логопед) | дүртенче | 60 |
| 3.19. | Өлкән тәрбияче | дүртенче | 60 |
| Структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 4.1. | Структура бүлекчәсе мөдире (башлыгы): гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү белем бирү программасын гамәлгә ашыручы кабинет,лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-производство) остаханәсе һәм башка структура бүлекчәләре (икенче квалификация дәрәҗәсенә караган структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш), | беренче | 65 |
| 4.2. | Балалар өчен өстәмә белем бирү программасын һәм белем бирү программасын тормышка ашыручы аерым структура бүлекчәсе мөдире (башлыгы): кабинет,лаборатория, | икенче | 70 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-производство) остаханәсе һәм башка структура бүлекчәләре (өченче квалификация дәрәҗәсенә караган структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларыннан тыш) башлыгы (мөдире, директоры, җитәкчесе, идарәчесе) | | |

14 нче таблица

Медицина хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| N т / б | Вазыйфа исеме | Квалификация дәрәҗәсе | Үлчәм коэффициентлары ның иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|---|
| Урта медицина һәм фармацевтика персоналы вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 1.1. | Диета буенча шәфкать туташы (диета буенча медбрат) | икенче | 37 |
| 1.2. | Шәфкать туташы (медбрат) | өченче | 40 |
| 1.3. | Массаж шәфкать туташы (массаж медбраты) | өченче | 40 |
| Табиблар һәм провизорлар вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | | |
| 2.1. | Белгеч табиблар (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсендәге белгеч табиблардан кала) | икенче | 60 |

15 нче таблица

Мәдәният хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге критерийлары буенча үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме

| N т / б | Вазыйфа исеме | Үлчәм коэффициентларының иң чик җыелма күләме |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Техник башкаручылар һәм ярдәмче состав артистлары вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| 1.1. | Билет тикшерүчеләр | 5 |
| Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| 2.1. | Аккомпаниатор | 35 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2. | Костюмнар бүлмәсе мөдире | 35 |
| 2.3. | Мәдәни оештыручы | 35 |
| 2.4. | Түгәрәк, һәвәскәрләр берләшмәсе, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | 35 |
| Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| 3.1. | Аккомпаниатор-концертмейстер | 40 |
| 3.2. | Тавыш операторы | 40 |
| 3.3. | Кинооператор | 40 |
| 3.4. | Китапханә, музей һәм башка шундый учреждение һәм оешмалар редакторы | 40 |
| 3.5. | Клуб эше методикасы белгече | 40 |
| 3.6. | Яктырту рәссамы | 45 |
| 3.7. | Рәссам-декоратор | 45 |
| 3.8. | Рәссам-бизәүче | 45 |
| 3.9. | Рәссам-фотограф | 45 |
| 3.10 | Труппа мөдире | 45 |
| 3.11 | Вокал буенча репетитор | 45 |
| 3.12 | Балет артисты | 45 |
| 3.13 | Драма артисты | 45 |
| 3.14 | Симфония, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестрлар, халык уен кораллары оркестры артисты | 45 |
| Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре җитәкчеләре составы вазыйфалары һөнәри квалификация төркеме | | |
| 4.1. | Мәдәният йорты (сарае), мәдәният һәм ял паркы, халык иҗаты фәнни-методик үзәге, халык иҗаты йорты, халык мәдәнияте (мәдәният һәм ял) үзәге һәм башка шундый учреждение һәм оешмаларның бүлек (сектор) мөдире | 50 |

| | | |
|---|---|---|
| 4.2. | Тавыш режиссеры | 50 |
| 4.3. | Режиссер-куючы | 55 |
| 4.4. | Режиссер (дирижер, балетмейстер, хормейстер) | 55 |
| 4.5. | Массакүләм тамашалар режиссеры | 55 |
| 4.6. | Сәнгать җитәкчесе | 55 |
| 4.7. | Баш дирижер | 55 |
| 4.8. | Баш режиссер | 55 |
| 4.9. | Әдәбият- драматургия бүлеге җитәкчесе | 55 |
| 4.10 | Сәнгать - кую бүлеге мөдире | 55 |
| 4.11 | Музыка бүлеге мөдире | 55 |

45. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә башкарылган эш сыйфаты ($FOT_k$) өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр фонды төзелә, аның күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT_k = FOT_{do} \times \frac{D_k}{100\%},$$

монда

$FOT_{do}$ - төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи оклады буенча яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фонды;

$D_k$ - хезмәткә түләү фондының башкарылган эш сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләре өчен өлеше.

Башкарылган эшнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләргә хезмәткә түләү фондының тәкъдим ителә торган күләме төп эш урыны буенча хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары буенча яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фондының 10 проценты күләмендә кабул ителә.

## 8 бүлек. Компенсация характерындагы түләүләр

46. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә компенсация характерындагы түләүләргә керә:

1) зыянлы һәм (яки) куркыныч эш шартларында эшләгән хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр;

2) нормаль (төрле квалификация эшләрен башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, дәрестән тыш, төнге вакытта һәм нормаль эштән

читләшкән башка шартларда эшләгәндә) эш өчен компенсация характерындагы түләүләр.

47.Компенсация характерындагы түләүләр, аларны гамәлгә ашыру күләмнәре һәм шартлары хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормалары булган башка норматив хокукый актлар нигезендә күмәк шартнамәләр, локаль норматив актлар, хезмәт шартнамәсе белән билгеләнә.

48. Зыянлы һәм (яки) куркыныч эш шартларында эшләгән хезмәткәрләргә компенсация характерындагы түләүләр формула буенча исәпләнә ($B_{kh}$):

$$B_{kh} = O_b \times \frac{D_{kh}}{100\%} \times \frac{H_{fk}}{H_n},$$

монда

$O_b$- яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренең база оклады күләме;

$D_{kh}$ - Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы нигезендә кабул ителгән компенсация харакҗерындагы түләүләр өчен өстәмә күләме;

$H_{fk}$ - законнарда компенсация характерындагы түләүләр каралган фактта эшләнгән вакыт (ставка).

$H_n$ - яшьләр эшләре учреждениеләрендә эшләүчеләрнең база оклады өчен сәгатьләр нормасы.

Зыянлы һәм (яки) куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы, нормаль эш шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы белән чагыштырганда, хезмәт шартларын махсус бәяләү нигезендә, база (вазыйфаи) окладының 4 проценты күләмендә арттырып билгеләнә.

49. Нормаль шартлардан читләшкән шартларда эшләгән өчен (төрле квалификациядәге эшләрне башкарганда, һөнәрләрне (вазыйфаларны) берләштергәндә, эштән тыш эшләгән өчен, төнге вакытта эшләгән өчен һәм нормаль шартлардан читләшкән башка шартларда эшләгән өчен) түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## 9 бүлек. Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесенең, җитәкче урынбасары һәм баш бухгалтерның хезмәт хакын билгеләү тәртибе

50. Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының һәм баш бухгалтерларының хезмәт хакы вазыйфаи оклад, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрдән тора.

51. Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесенең вазыйфаи оклады ($O_d$) Башкарма комитет тарафыннан елга бер тапкыр агымдагы елның 1 гыйнварына яисә хезмәт өчен түләү буенча төркемгә бәйле рәвештә оешма төзелгән датага билгеләнә һәм түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_d = O_b \times H_n,$$

монда

$O_b$ - җитәкченең база окладры күләме;

$H_n$ - әлеге вазыйфа буенча ставка нигезендә база окладры өчен сәгатьләр нормасы.

Яшьләр эшләре учреждениеләрендә җитәкченең хезмәтенә түләү төркеме яшьләр эшләре учреждениеләрендә эшләүчеләрнең штат санына карап билгеләнә.

52. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә җитәкче урынбасарларының һәм баш бухгалтерларның вазыйфаи окладры оешмалар җитәкчеләренең вазыйфаи окладыннан 20-30 процентка түбәнрәк итеп билгеләнә.

53. Җитәкчеләрнең хезмәтенә түләү төркеме, җитәкчеләрнең база окладлары күләме 16 нчы таблицада күрсәтелгән.

16 нчы таблица

Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчеләренең база окладры күләме;

| N т / б | Оешма төренең исеме / Оешманың штат саны, берәмлекләр | Хезмәткә түләү төркеме | Җитәкченең окладры <*> , сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Яшьләр үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 30 000 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 33 700 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (50 не кертеп) | 3 | 38 200 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 51 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 40 900 |
| | 71 дән 150 гә кадәр (150 не кертеп) | 5 | 42 700 |
| | 151 дән | 6 | 48 200 |
| 2. | Сәламәтлек - ял итү учреждениеләре (лагерьлар) | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 32 000 |
| | 11 дән | 2 | 34 500 |
| 3. | Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары | | |
| | 12 гә кадәр (12 не кертеп) | 1 | 30 000 |
| | 13 тән 25 кә кадәр (25 не кертеп) | 2 | 34 500 |
| | 26 дан 40 ка кадәр (40 ны кертеп) | 3 | 39 100 |
| | 41 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 40 900 |
| | 71 дән 140 ка кадәр (140 ны кертеп) | 5 | 43 700 |
| | 141 дән | 6 | 64 500 |
| 4. | Хәрби-патриотик эш һәм яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 25 000 |
| | 11 дән 20 гә кадәр (20 не кертеп) | 2 | 33 400 |
| | 21 дән | 3 | 41 800 |
| 5. | Җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 31 500 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 36 400 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (50 не кертеп) | 3 | 37 400 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 51 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 38 400 |
| | 71 дән 90 га кадәр (90 ны кертеп) | 5 | 39 400 |
| | 91 дән | 6 | 40 400 |
| 6. | Балаларның һәм яшүсмерләрне сәламәтләндерүне, ялын һәм мәшгульлеген оештыру үзәкләре | | |
| | 45 кә кадәр (45 не кертеп) | 1 | 39 000 |
| | 46 дан 90 га кадәр (90 ны кертеп) | 2 | 43 000 |
| | 91 дән | 3 | 47 000 |
| 7. | Студентларның хезмәт отрядлары үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 37 200 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 38 200 |
| | 31 дән | 3 | 39 200 |
| 8. | Балаларга һәм яшьләргә психологик- педагогик ярдәм үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 38 100 |
| | 11 дән 25 кә кадәр (25 не кертеп) | 2 | 41 100 |
| | 26 дан | 3 | 44 100 |
| 9. | Балалар һәм яшьләр өчен телефон аша ашыгыч психологик ярдәм үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 37 000 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 41 000 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (50 не кертеп) | 3 | 45 000 |
| | 51 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 49 000 |
| | 71 дән | 5 | 54 000 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10. | Девиант тәртипле балалар өчен социаль - реабилитация үзәге | | |
| | 20 гә кадәр | 1 | 44 000 |
| | 21 дән 40 ка кадәр (40 ны кертеп) | 2 | 46 000 |
| | 41 дән 60 ка кадәр (60 ны кертеп) | 3 | 48 000 |
| | 61 дән | 4 | 50 000 |
| 11. | Яшьләргә ярдәм үзәкләре | | |
| | 12 гә кадәр (12 не кертеп) | 1 | 30 000 |
| | 13 тән 25 кә кадәр (25 не кертеп) | 2 | 34 500 |
| | 26 дан 40 ка кадәр (40 ны кертеп) | 3 | 39 100 |
| | 41 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 40 900 |
| | 71 дән 140ка кадәр (140 ны кертеп) | 5 | 43 700 |
| | 141 дән | 6 | 64 500 |
| 12. | Республика яшьләр, инновацияләр һәм профилактика программалары үзәкләре | | |
| | 10 га кадәр (10 ны кертеп) | 1 | 30 000 |
| | 11 дән 30 га кадәр (30 ны кертеп) | 2 | 33 700 |
| | 31 дән 50 гә кадәр (50 не кертеп) | 3 | 38 200 |
| | 51 дән 70 кә кадәр (70 не кертеп) | 4 | 40 900 |
| | 71 дән 150 гә кадәр(150 не кертеп) | 5 | 42 700 |
| | 151 дән | 6 | 48 200 |

--------------------------------

<*> Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчеләре өчен башкарыла торган

| |
|---|
| эшләрнең катлаулылыгын һәм әһәмиятен исәпкә алып, шулай ук яшьләр эшләре учреждениеләренә эшчәнлек профиле буенча оештыру һәм методик ярдәм күрсәтүгә бәйле рәвештә база окладына карата 1,1 күләмендә арттыру коэффициенты билгеләнә. |

54. Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчеләренә башкарылган эш сыйфаты өчен стимулдаштыру характерындагы түләүләр Башкарма комитет тарафыннан эш критерийлары нигезендә билгеләнгән эш нәтиҗәләрен исәпкә алып билгеләнә.

Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин.

55. Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесе урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләр, аларның эшчәнлек нәтиҗәлелеге критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесе урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, еллык эш йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен түләнергә мөмкин.

56. Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчеләренең эш критерийлары һәм аларның үлчәм коэффициентлары Башкарма комитет тарафыннан раслана.

Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчеләре урынбасарлары һәм баш бухгалтерлары өчен эш критерийлары һәм аларның үлчәм коэффициентлары оешма җитәкчесе тарафыннан раслана.

57. Башкарылган эш сыйфаты өчен түләүләр ($В_k$) формула ярдәмендә исәпләнә:

$$В_k = В_C \times К_{VK},$$

монда

$В_C$ - яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесенең (җитәкче урынбасарларының һәм баш бухгалтерының) вазыйфаи окладының 20 проценты күләмендә стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме;

$К_{ВК}$ - сыйфат критерийларын үтәү коэффициенты.

58. Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесенә башка стимуллаштыру характерындагы түләүләр Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесе, аның урынбасарлары, баш бухгалтеры на компенсация характерындагы түләүләр Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә билгеләнә.

## 10 бүлек. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

59. Яшьләр эшләре учреждениеләрендә хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына яшьләр эшләре учреждениеләренең норматив чыгымнар, кулланучылар һәм хезмәт күрсәтүләр саны, башкарыла торган эшләр нигезендә билгеләнгән акчалары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм яшьләр эшләре учреждениеләрендәге финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яисә бюджет сметасында чагыла.

60. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладлар, компенсация һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәрләренә (эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләрен дә кертеп) финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган яисә яшьләр эшләре учреждениеләренең агымдагы финанс елына хезмәт өчен түләүгә бюджет сметасы средстволар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

61. Яшьләр эшләре учреждениеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбеннән, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәт өчен түләү фондын экономияләү тиешле чорда (ай, квартал, ел) яшьләр эшләре учреждениеләренең әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә стимуллаштыру түләүләренә юнәлтелергә мөмкин.

Хезмәт өчен түләү фонды экономияләнгән очракта стимуллаштыру түләүләре хезмәт өчен түләү фондын экономияләү барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә (эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары хезмәткәрләрен дә кертеп) башкарыла.

Хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә яшьләр эшләре учреждениеләре хезмәткәренә хезмәт нормаларын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән эш вакыты нормасын исәпкә алып, тиешле чорда хезмәткә түләү фондын экономияләү исәбенә башкарылган стимуллаштыру түләве күләме «Минималь хезмәт хакы турында» 2000 елның 19 июнендәге 82-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән хезмәткә түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчесеннән кала).

Яшьләр эшләре учреждениеләре җитәкчеләренә хезмәт өчен түләү фондын экономияләү исәбенә стимуллаштыру түләве күләме Башкарма комитет тарафыннан билгеләнә.

Яшьләр эшләре учреждениеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында финанс белән тәэмин итүнең барлык чыганаклары исәбеннән, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, барлыкка килгән хезмәткә түләү фонды экономиясеннән файдалану өчен җаваплылык яшьләр эшләре учреждениесе җитәкчесенә йөкләнә.

Яшьләр эшләре шәһәр муниципаль учреждениеләре җитәкчеләренә һәм хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмәгә кушымта

1 нче таблица

Физик культура хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү мөмкинлеген бирә торган мактаулы исемнәр, спорт исемнәре исемлеге

| N т / б | Исем |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.2. | Россиянең атказанган спорт мастеры |
| 1.3. | Россиянең атказанган тренеры |
| 1.4. | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 1.5. | Россиянең халыкара классны атказанган спорт мастеры |
| 1.6. | Россиянең халыкара класслы спорт мастеры |
| 1.7. | Россия спорт мастеры |
| 1.8. | Россия гроссмейстеры |
| 1.9. | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 2. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 2.1. | Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре |
| 2.2. | Татарстан Республикасының атказанган тренеры |
| 3. Совет Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 3.1. | СССРның атказанган спорт мастеры |
| 3.2. | СССРның атказанган тренеры |
| 3.3. | СССРның спорт мастеры |
| 3.4. | СССРның халыкара класслы спорт мастеры |

| | |
|---|---|
| 3.5. | СССР гроссмейстеры |
| 4. Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы республикаларының мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2. | Атказанган  спорт эшлеклесе |
| 4.3. | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 4.4. | Атказанган физкультура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.5. | Атказанган тренер |
| 5. Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы  автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 5.2. | Атказанган физкультура һәм спорт хезмәткәре |

2 нче таблица

Мәгариф  хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү мөмкинлеген бирә торган мактаулы исемнәр, спорт исемнәре һәм ведомство бүләкләре исемлеге

| N т / б | Исем |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Россия Федерациясенең мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең халык укытучысы |
| 1.2. | Россия Федерациясенең атказанган укытучысы |
| 1.3. | Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе |
| 1.4. | Россия Федерациясе югары мәктәбенең атказанган  хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең атказанган производствога өйрәтү мастеры |
| 1.6. | Россия Федерациясенең атказанган физик культура хезмәткәре |
| 1.7. | Россия Федерациясенең атказанган  мәдәният хезмәткәре |
| 1.8. | Россия Федерациясенең атказанган рәссамы |

| | |
|---|---|
| 1.9. | Россиянең атказанган спорт мастеры |
| 1.10. | Россиянең атказанган тренеры |
| 1.11. | Россиянең халыкара класслы атказанган спорт мастеры |
| 1.12. | Россиянең халыкара класслы спорт мастеры |
| 1.13. | Россия спорт мастеры |
| 1.14. | Россия гроссмейстеры |
| 1.15. | Россиянең мактаулы спорт судьясы |
| 2. Совет Социалистик Республикалары Союзының мактаулы исемнәре, спорт исемнәре | |
| 2.1. | СССРның халык укытучысы |
| 2.2. | СССРның атказанган спорт мастеры |
| 2.3. | СССРның атказанган тренеры |
| 2.4. | СССРның спорт мастеры |
| 2.5. | СССРның халыкара класслы спорт мастеры |
| 2.6. | СССР гроссмейстеры |
| 3. Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы республикаларының мактаулы исемнәре | |
| 3.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 3.2. | Атказанган спорт эшлеклесе |
| 3.3. | Атказанган физик культура эшлеклесе |
| 3.4. | Атказанган физкультура һәм спорт хезмәткәре |
| 3.5. | Атказанган тренер |
| 3.6. | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 3.7. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү укытучысы |
| 3.8. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 3.9. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 3.10. | Атказанганукытучы |

| | |
|---|---|
| 3.11. | Атказанган югары  мәктәп хезмәткәре |
| 3.12. | Атказанган халык мәгарифе хезмәткәре |
| 3.13. | Атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 3.14. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 3.15. | Атказанган фән  эшлеклесе |
| 4. Совет Социалистик Республикалары Союзы составындагы  автономияле республикаларның мактаулы исемнәре | |
| 4.1. | Атказанган физкультура һәм спорт эшлеклесе |
| 4.2. | Атказанган физкультура һәм спорт хезмәткәре |
| 4.3. | Атказанган мәктәп эшлеклесе |
| 4.4. | Атказанган мәктәп укытучысы |
| 4.5. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү  укытучысы |
| 4.6. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү мастеры |
| 4.7. | Атказанган һөнәри-техник белем бирү хезмәткәре |
| 4.8. | Атказанган югары  мәктәп хезмәткәре |
| 4.9. | Атказанган фән һәм мәдәният эшлеклесе |
| 4.10. | Атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 4.11. | Атказанган фән һәм техника эшлеклесе |
| 4.12. | Атказанган фән  эшлеклесе |
| 4.13. | Атказанган тренер |
| 5. Татарстан Республикасының мактаулы исемнәре | |
| 5.1. | Татарстан Республикасының халык укытучысы |
| 5.2. | Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы |
| 5.3. | Татарстан Республикасының атказанган укытучысы |
| 5.4. | Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе |
| 5.5. | Татарстан Республикасының атказанган югары мәктәп хезмәткәре |
| 5.6. | Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре |

| | |
|---|---|
| 5.7. | Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре |
| 5.8. | Татарстан Республикасының атказанган тренеры |
| 5.9. | Татарстан Республикасының атказанган яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәре |
| Россия Федерациясенең ведомство бүләкләре, Совет Социалистик Республикалары Союзының ведомство бүләкләре, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре. | |
| 1. Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.2. | Россия Федерациясенең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
